ЭШКӘ – АШ

Фермерлар һәм кооперативлар нинди дәүләт ярдәменнән файдалана ала?

> 2

СУДАНМЫ, ЮЛДАНМЫ?

Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тармакның яңалыклары белән таныштырды

> 2

ТИМЕРНЕ «ТЕРЕЛТҮЧЕ»

Кукмара районы Камышлы авылында яшәүче Тәлгать Әүхәдиев һәрбер техниканың көен белә

> 4

ХАЛЫКЧАН ҖЫРЧЫ

Эльмира Сөләйманова тамашачы күңелендә шулай сакланыр

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 187 (28960) | Шимбә | 17 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сәламәтлек

Чир узды бугай дигән өметләр акланмады. Республикада кискен респиратор вируслы инфекцияләр (ОРВИ) һәм грипп белән авыручылар саны арта. Белгечләрнең вазгыятьнең кискенләшәчәге турында фаразлары рас булып чыкты. Битлекле, карантинлы чакка кире кайтып барышыбызмы? Чир йоктырсаң, нишләргә? Авырмас өчен, нинди киңәшләрне истә тотарга?

vk.com

ОНЫТЫЛДЫ, ДИМӘ!

Өлешчә чикләүләр

Вазгыятьне чамалар өчен, статистик мәгълүматларга күз салыйк. Республикада ОРВИ һәм гripптан авыручылар саны эпидемиологик чиктән 82 процентка югарырак. Язма әзерләнгән вакытта алган мәгълүматлар буенча, гриппның 198 очрагы теркәлгән, шуларның 92 проценты «дуңгыз гриппы»на туры килә.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы карары нигезендә республикада өлешчә мәҗбүри битлек режимы кертелә. Медицина оешмаларында эшләүчеләр һәм анда килүчеләр, социаль һәм мәгариф учреждениеләрендәгеләргә битлек кию мәҗбүри булачак. Моннан тыш стационарда дәваланучылар янына килеп йөрү (кыен хәлдәге сырхауларны караучыларга кагылмый) тыела. Моңа өстәп, балалар бакчасы, мәктәп, институт һәм башка белем бирү оешмаларында, коллективта авыру күрсәткече 20 проценттан артып киткән очракта, укыту туктатылачак. Сүз уңаеннан, республикада авырулар арту сәбәпле тулысынча ябылган мәктәпләр юк. Ләкин 48 мәктәптә 142 сыйныфны карантинга җибәргәннәр. Чаллыда, гомумән, 17 декабрьне «Сәламәтлек көне» дип игълан иттеләр. Бу көнне дәресләр укытылмый.

Россия күләмендә дә хәлләр шул чама. Илнең баш санитар табибы Анна Попова хәбәр иткәнчә, ОРВИ һәм грипп белән авыручыларның атна саен 30–35 процентка артуы күзәтелә. «Дуңгыз гриппы» дигәне өстенлек итә. Кайбер төбәкләрдә мәктәпләр дә, балалар бакчалары да эшләми.

Россия Президенты Владимир Путин исә бу вазгыятькә бәйле рәвештә: «Кыш озын. Яз башы да суык була әле. Иммунизация, вакцинацияне дәвам иттерергә, кешеләрне бу чирләрдән сакларга кирәк», – диде. Үзе дә прививка ясатуын әйтте.

Илнең сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко китергән саннар тагын да хәвефлерәк. Әйтик, атна эчендә табибларга 1,5 млн кеше мөрәҗәгать иткән. Чир йоктыручылар арасында грипп билгеләре булганнар 50 процентны тәшкил итә. Шуларның 23 проценты – 7–14 яшьлек балалар, 18 процент чамасы – мәктәп яшенә кадәрге сабыйлар.

Блогер Ринат Галиәхмәтов гаиләсе дә шушы көннәрдә авырган.

– Кем белән сөйләшмә, барысы да чирли. Ниндидер күмәк авыру бу! Без дә бер айлап шулай интегәбез инде, – дип сөйләде Ринат. – Кызыбыз Сәфинә балалар бакчасына йөри башлады. Әллә ни озак йөрмәде дә. Күзендә конъюнктивит башланды. Аннан безгә дә эләкте. Баланың бер көнне температурасы 40ка кадәр күтәрелде. Табиб, вирус эләктергәнсез, ОРВИ, диде. Аннан ике көн минем температурам булды. Эшкә дә йөри алмадым. Баштарак коры ютәл белән интектек. Шулкадәр мәгънәсез, ямьсез йөткерү! Беркем белән очрашасы, чараларга да йөрисе килми. Йөткереп утыру матур түгел бит инде. Әле Сәфинә һаман чирли. Эчмәгән дару калмады. Цинк эчәбез. Кешеләр күп булган җирләргә йөрмәскә тырышабыз.

Фараз һәм өмет

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш инфекционисты Халит Хәйретдинов әйтүенчә, хәзер гриппның традицион күтәрелеш чоры күзәтелә. Коронавируска кадәр вакытны искә алсак, декабрь, гыйнвар, февраль айларында бу даими булган.

– Күпчелек коронавирус белән чирләп алды. Димәк, хәзер бүтән авыруларга карата «иммун бурыч»ны кайтарырга кирәк. Шуңа да ОРВИ һәм грипп белән чирләүчеләрнең күп булуын күрәбез. Бу – көтелгән хәл, – дип саный белгеч. – «Дуңгыз гриппы» безгә 2009 елда килеп керде. Башта ул куркынычрак та иде әле. Чөнки безнең өчен яңа вирус иде.

Халит Хәйретдинов искәрткәнчә, «дуңгыз гриппы» вакытында кешенең тән температурасы кисәк күтәрелә һәм югары күрсәткечләрдә тора. Баш, тән, буыннар сызлау күзәтелә, күз алмалары авырта.

Белгеч әйтүенчә, авырмас өчен ике юл бар. Берсе – вакцина ясату, икенчесе – үзеңне саклау. Ягъни кеше күп йөри торган җирләргә барудан тыелып тору, социаль ара саклау, битлек кию. Гадәттә, грипп эпидемиясе 8 атна дәвам итә.

> **Марат САДЫЙКОВ,**
> **Татарстанның сәламәтлек саклау министры:**
> – Грипп белән авыручылар саны арта бара. Аның шулай буласы билгеле иде инде. Соңгы ике елда грипп йоктыру очраклары күзәтелмәде, халыкның иммунитеты кимеде. Бүген безне грипп та, коронавирус та сагалый. Аларның билгеләре күпмедер дәрәҗәдә охшаш булса да, дәвалау алымнары шактый аерыла. Ковид вакытында кан сыеклаучы чаралар кулланылса, грипп вакытында геморрагик синдромнан котылырга кирәк. Гripптан саклану өчен гади генә кагыйдәләрне үтәү зарур. Иң мөһиме – температураң күтәрелгән икән, эшкә, укырга барырга ярамый. Тиз арада дәвалана башларга кирәк.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының эпидемиология һәм иммунопрофилактика буенча баш белгече Дмитрий Лопушов әйтүенчә, «дуңгыз гриппы»н организм онытып та бетергән булу ихтимал. Шуңа аңа каршы көрәшерлек иммунитет та кимегән.

– Соңгы елларда грипп белән авыру, күп булмаса да, берән-сәрән теркәлә иде. Хәзер халыкның күпчелегендә аңа каршы иммунитет бөтенләй юк яисә юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә чирләүчеләр артуын күзәтәбез дә инде, «дуңгыз гриппы»ның өстенлек итүе сагайта, – дип аңлата белгеч.

Ахыры 2 нче биттә >

Махсус урыннары бар

Татарстанда Яңа ел бәйрәмнәрендә салют аттыру өчен барлыгы 713 мәйданчык ачылачак. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчесе урынбасары Сергей Сергеев кисәтеп әйткәнчә, салютлар һәм башка пиротехниканы күпфатирлы йортлар, шәхси йортлар, торак-коммуналь хуҗалык объектлары тирәсендә, кешеләр күпләп йөри торган урыннарда куллану тыела.

Исегезгә төшерәбез: 19 декабрьдән республикада янгынга каршы махсус режим кертелә. Ул Яңа ел каникулы тәмамланганчы гамәлдә булачак. Бу чорда иминлек таләпләрен бозган өчен җаваплылык ике тапкыр арта. Шулай итеп, республикада яшәүчеләргә штраф күләме 10 мең сумнан 20 мең сумга җитә. Эшмәкәрләр янгынга каршы кагыйдәләрне бозган очракта 80 мең сум штраф түләячәк. Оешмалар – 800 мең сум.

Фаҗигаләр кимегән

Республикада ел башыннан бирле янгыннарда 114 кешенең гомере өзелгән. Бу сан узган елдагы белән чагыштырганда 29,19 процентка кимегән: ул чагында 161 кеше һәлак булган. Янгында җәрәхәтләнүчеләр саны да азрак – 184 кеше (узган елда – 199).

Быел Татарстанда барлыгы 4,8 мең янгын очрагы (узган елда – 5 902) теркәлгән.

Яңа ел бәйрәмнәре чорында янгын очраклары арту күзәтелә. Шуңа күрә озын ялларда аеруча сак булу таләп ителә.

Каешсызлык бәласе

Ел башыннан бирле Татарстанда юл фаҗигасендә 120 йөртүченең гомере өзелгән. 78енең үлеме сәбәбе – каршы як юлга чыгу. Татарстан Премьер-министры урынбасары Шамил Гафаров рәислегендә узган Хөкүмәт утырышында әйтелгәнчә, һәлак булган һәр өч йөртүченең берсе (37 кеше) иминлек каешын эләктермичә генә барган. Һәр бишесенең берсе исерек булган.

Юлларда тагын 87 пассажирның гомере өзелгән. 12се иминлек каешын эләктермәгән булган.

Ярминкә көне җитте

Бүген Казанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре гөрли. Шәһәр халкы иртәнге 6дан көндезге 12гә кадәр 15 мәйданчыкта чагыштырмача арзан бәядән фермер продукциясен сатып алу мөмкинлегенә ия.

Ярминкәдә 22 район һәм 18 авыл хуҗалыгы оешмасы катнаша. Бигрәк тә ит, бәрәңге, шикәр комы, он һәм йомыркага ихтыяҗ зур.

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре 10 сентябрьдән бирле һәр шимбә саен уздырылып килә. 14 ярминкә көнендә Казанга барлыгы 687,9 миллион сумлык азык-төлек кителгән.

Дулый буран

Казанга янә кар-буран килә. Шул ук вакытта ял көннәрендә шәһәрдә аномаль җылытачак, карлы яңгыр явып узачак. Аннары кинәт суытачак.

КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев әйтүенчә, шимбә-якшәмбедә шактый ук мул – айлык норманың 25 проценты чамасы явым-төшем көтелә. Якшәмбе көнне 0 градуска кадәр җылыта. Дүшәмбедә исә, кинәт суытып, юллар боз белән капланачак.

Профессор сүзләренә караганда, хәзер шәһәрдә тәүлеклек уртача температура –8…–9 градус тәшкил итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Финанс

Күктән алган сан түгел

Президент Рөстәм Миңнеханов республика казнасын ничек тулыландырырга мөмкин икәнен әйтте. Үз дигәннәренә ирешү өчен, район башлыкларын премия белән дә кызыксындырмакчылар. Татарстан Хөкүмәт йортында бюджет турында сөйләштеләр.

Министрлар Кабинетында Татарстан финанс, салым һәм казначылык органнарының 2022 елда тупланма бюджетның үтәлеш йомгаклары һәм киләсе елга бурычлар турында уртак коллегиясе узды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган чарада Россия финанс министры Антон Силуанов, Россия Салым федераль хезмәте җитәкчесе урынбасары Виктор Бациев, Федераль казначылык җитәкчесе урынбасары Александр Демидов та катнашты.

«Быел Татарстан тупланма бюджетының керемнәре 513 миллиард сум тәшкил итәчәк, дип фаразлана. Аның 420 миллиард сумы – үзебезнең керемнәр», – диде Рөстәм Миңнеханов. Чагыштыру өчен: узган ел тупланма бюджет керемнәре – 414 миллиард сум, республика бюджетына туры килгән өлеше исә 333 миллиард сум булган.

– Тик тынычланырга иртәрәк, вазгыять көтмәгәндә катлауланырга мөмкин. Салым органнары мәгълүматларына караганда, республика предприятиеләре күргән зыян быел 33,7 процентка арткан. Тотрыклылыкны саклап калу мөһим, – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, бу ел катлаулы шартларда узды. «Безнең предприятиеләр санкцияләргә бәйле кыенлыклар кичерә, алар сум курсы үзгәреп торган шартларда эшләргә мәҗбүр. Логистиканың яңа юлларын җайга салу, импортны алыштыруга бәйле эш тә дәвам итә. Безгә алга таба да җитештерүчеләр белән даими элемтәдә торырга кирәк. Төп бурыч аларның эшкә сәләтлелеген һәм үсешен тәэмин итүдән гыйбарәт», – диде Президент.

Киләсе ел бюджетын «киеренке» дип бәяләделәр киңәшмәдә. Тупланма бюджетның чыгымнары 531 миллиард сум, шул исәптән республиканыкы 467 миллиард сум тәшкил итәчәк, дип көтелә. Барлык чыгымнарның өчтән бер өлеше хезмәт хаклары түләүгә туры килә. «Татарстан бюджет җаваплылыгын тулысынча башкара», – диде Рөстәм Миңнеханов. Яңа бюджетның кәефне кыра торган өлеше – дефицит. Әлеге күрсәткеч 27 миллиард сум булыр, дип фаразлана. Җитешмәгән акчаны бүген үк эзли башларга кушты Рөстәм Миңнеханов. «Ямаулык»ны кайдан алырга мөмкин икәнен дә әйтте.

– 1 декабрьгә алынган мәгълүматларга караганда, салым буенча бурычлар 13,4 миллиард сум тәшкил итә. Бигрәк тә республиканың Төзелеш, архитектура һәм ТКХ, Сәнәгать һәм сәүдә, Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыкларына караган оешма-предприятиеләр арасында әҗәтчеләр саны арткан. Шуңа күрә һәр министрлыкка бу юнәлештә эшне көчәйтергә кирәк, – диде Президент. Кайбер шәһәр һәм район башлыкларына да җиңнәрен сызганырга туры киләчәк. Киңәшмәдә Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, Бөгелмә, Алабуга һәм Яшел Үзән районнарында бурычлылар саны артуы билгеле булды. «Глава»ларны алдан ук кызыктырып та куйдылар. «Салым буенча бурычларны җыю эшен яхшырткан өчен, ел азагында уңышка ирешкән муниципаль берәмлекләргә премия бирәчәкбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН,
Россия Президенты:

Тышкы басымнарга карамастан, без илебезнең үсешен тәэмин итүдән туктамаячакбыз. Алай гына да түгел, без, һичшиксез, тагын да көчлерәк булып, яңа уңышлы проектлар тормышка ашыру өчен тырышачакбыз, Россияне тагын да югарырак технологик дәрәҗәгә чыгарачакбыз. Илнең икътисади, финанс, технологик һәм кадрлар суверенитетын тәэмин итәчәкбез.

(Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар советы утырышында ясаган чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – БАЛАЛАР

«Меркатор» белгечләре Россиядә 2021 елда туган балалар арасында кемнәр күбрәк булуын ачыклаган.



Барлыгы – 1,4 млн бала
Малайлар – 720 мең
Кызлар – 678 мең

- >> гаиләдә беренче бала
- >> икенче бала
- >> өченче бала
- >> дүрт һәм аннан да күбрәк

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Безне коткарачак мәдәният

Кеше затын кеше итеп тоткан алтын багана бар. Ул да булса – мәдәният. Мәңгелеккә карап иҗат ителгән кабатланмас әдәби әсәрләр, даһи рәссамнар ясаган мәшһүр картиналар, гасырлар да моңын җуйдыра алмаган көйләр, сынлы сәнгать, театр сәнгате үрнәкләре, башкалар. Иҗат әһелләре тудырганның затлыдан-затлылары алдында вакыт көчсез. Кешелектә кешелек кыйммәтләре сакланып килгәндә, шулай булырга тиеш тә. Ул гынамы, мәдәни мирас, җыелган мәдәни хәзинә вакыт үткән саен тулыланып, артып торырга, идеалда аның бәндәгә йогынтысы, тәэсире дә чордан-чорга көчәя барырга, иҗатчылар үзләре дә күбәя торырга тиеш кебек.

Ләкин тулылану һәм йогынты, дигәндә соңгы ярты гасыр аксау чорын хәтерләтмиме? Бүгенге ашкын заманда мәдәният җәүһәрләренә игътибар, соклану тиешле дәрәҗәдәме? Әлеге ике сораугa уңай җавап бирергә мин ашыкмас идем. Кистереп җавап биреп булмый торган сораулар әле тагын да бар. Бөек сәнгать әсәрләрен, фикер ияләре язган затлы китапларны күрмичә, күрергә теләмичә, без ялгышларыбызны куертмыйбызмы, киләчәкне шик астына куймыйбызмы? Мәдәният безне коткарсын өчен, бүген аның үзен коткару турында уйлар, йогынтысын саклар вакытлар җитмәдеме?

Достоевский гасыр ярым элек «Матурлык кешелекне коткарачак», – дип язган. Бүген матурлыкның үзен саклар вакытлар ишек шакый кебек. Бүген шоу-бизнес дип аталган заман зәхмәте җыр сәнгатен басып, кысрыклап килмиме? Музейларга, рәсем галереяларына йөрүчеләр саны яши-яши кимемиме? Шул ук Достоевскийны, яисә Шекспирны, үзебезнең Гаяз Исхакыйны укучылар нигә көннән-көн азая? Калын романнар уку соңгы чирек гасырда модадан тәмам чыкты. Бүгенге адәми затка тирәнлек, нәрсәдер турында озаклап уйлану хас түгел. Мәгълүмат күп, ул көн туса башка ишелеп тора. Кеше игътибарына ирешсен өчен, аны кыска форматка – клип рәвешенә китерәләр. «Клиплы фикерләү» («клиповое мышление») – соңгы чирек гасыр продукты. Тирәнлек булмау гавамны җилбәзәк итә. Ул аны надан да итә. Ул аны җан-фәрманга дөнья кудырта, акча артыннан йөртеп кенә калмый, «күсе чабышы» дип аталган туймас тамаклык ярышында, байлык, комфорт өчен барган мәгънәсез узышта да катнаштыра. Кая монда балетка, Шекспир драмаларына, Репин картиналарына урын?..

Безне коткарырга тиешле матурлык. Матурлык ул – шул ук мәдәният. Кеше затын рухиятле, затлы, ипле итәргә алынган өлкә. Кешелек тудырган кыйммәтләр арасында мәдәният, ул бар иткән затлылык белән тиңләшерлек һичнәрсә, башка төр гүзәллек, камиллек юк. Мәдәният, аның җәүһәрләре – кешелек дөньясының төп казанышы, кешене һәрчак яктыга, яхшыга өндәп торучы, аңа юл күрсәтүче маяк. Бәс шулай икән, ник аның кадере аз? Тормыш яшәгән саен вакլансын да ди. Тик ул хәл безне иплелектән, гармониядән ерагайта барырга, мәдәният дигән маякны кыйбла итүдән туктатып, киләчәгебезне шик астына куярга тиеш түгелдер.

Мәдәният юкка чыга икән, кешелек цивилизациясеннән дә бернәрсә калмаячак. Җир шары адәми затның мин-минлеге, табигать белән санлашмавы аркасында йә чүлгә – тереклек ияләре яшәмәс хәлгә җитәчәк, йә, яшәр шартлар калганда, кешеләр бер-берсенә сәбәпсез ташланырга әзер кыргый җанварлар йортына әвереләчәк. Шуны телибезме без? Андый хәлләр булмасын, дөнья мең тапкыр караңгырак яңа Урта гасырларга чуммасын дигәндә, рухияткә, аның шифалы чишмәсе булган мәдәнияткә игътибар бүген бермә-бер артыграк, киң колачлырак булсын иде дә бит…

Мәдәният дигәндә, кайчагында русчадан алынган «культура» кәлимәсе кулланыла. Тик әлеге сүзләр арасына тәңгәллек билгесе куеп булмый. Чөнки культура дигәнебез киңрәк өлкәне колачлый булыр. Культурага мәдәнияттән тыш әле тагын, мәсәлән, шул ук динне, фәнне, кануннарны, әхлак нормаларын, хәтта көнкүреш предметлары белән хезмәт коралларын да кертәләр. Саналганнарның затлылыгы, кыйммәте турында нидер әйтү, аларны бәяләү кыен. Чөнки чорына, иленә карап, алар үзгәрә, алышынып тора. Ә кешелек чорлар, гасырлар буе туплап килгән мәдәният җәүһәрләре, әйтүебезчә, мәңгелек. Аларга табыну күмәк төс алганда гына кешелекнең бәхетле буласына шик юктыр ул.

Игелек, шәфкать, гаделлек, ярату, миһербан… Бу асыл сыйфатларның барысы да – культуралылык һәм мәдәниятлелек билгеләре. Алар юк икән, «кеше» дигән җан иясенең базар көнне поты бер тиен. Шулай булгач, җәмгыять нигезендә икътисадтан да алда мәдәният ятарга, мәдәният беренчел булырга тиеш түгел микән? Яшәешебездә мәдәният диктатурасы тудырганда гына без кешелекнең мәңгелек хыялы – алтын гасырга якынлаша алырбыз кебек. Моны, ни кызганыч, азлар аңлый. Дөнья дәүләтләргә бүленгән һәм аларның күбесе бүгенге көн белән яши – һәр ил үзенчә «акылдан яза». Дәүләт җитәкчеләренең үз илен икътисадый яктан үстерәсе, шуның аша халкын «бәхет»кә чыгарасы килә. Дөнья халыкларының абсолют күпчелегенең тамагы тук, өсте бөтен булуга карамастан. Илләр арасында даими тарткалаш барганлыктан, хәрби көч тә икътисад көче аша исәпләнелә: технологияләр яңарып тора, көрәш кыза. Мәдәният кайгысы, гавамны затлы, гыйлемле итү, кешелеклелек тәрбияләү – власть өчен унынчы кайгы.

Кыйммәтләр иерархиясендә аерым тарафларда икътисадтан кала әле «милли идеология» дигән «мәдәният» тә очрап тора. Анысы – халыкны идеология аша «идейный» итеп, дәүләтне көчәйтергә алыну – гомумән дә куркыныч. Тар даирә уйлап табып гамәлгә керткән тәгълимат белән исереп яшәү ул – мәдәнияттән ераклашу гына түгел, фаҗигагә ашкыну да. Үткән гасырда гына аерым илләрнең коммунизм белән, шакшыдан да шакшы идеология – нацизм белән чирләп китеп, гомумкешелек кыйммәтләреннән баш тартканын, нәтиҗәдә үзләрен генә түгел, башкаларны да бөек тетрәнүләргә җиткергәнен беләбез. Язманы заманында Россия Мәдәният фондын җитәкләгән күренекле галим-культуролог Дмитрий Лихачев сүзләре белән тәмамлыйсым килә: «Общенациональная идея в качестве панацеи от всех бед – это не просто глупость, это крайне опасная глупость! Главной заботой государства, власти должна быть не химера национальной идеи, а культура».

КҮКТӘН АЛГАН САН ТҮГЕЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ел азагына кадәр республика предприятиеләре 4,8 триллион сумлык продукция җитештерер, дип көтелә. «Бу күрсәткечне 5 триллион сумга җиткерергә хыяллана идек, күп калмады. Алга таба 10 триллион сумга омтылачакбыз. Болай булса, үз-үзебезне тәэмин итү мөмкинлеге тагын да артачак», – диде Президент.

Сер түгел, киләсе ел бюджетын төзегәндә дә республиканың әйдәп бара торган оешма-предприятиеләренә зур өмет баглаганнар. «Хәлләр сез уйлаганнан начаррак килеп чыкса, казнаны ничек тулыландырырга икәнен алдан фаразладыгызмы?» – дип тә сорады Антон Силуанов быелгы бюджет үтәлеше һәм киләсе елга бурычлар турында хисап тоткан Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллиннан. Министр сүзләренә караганда, бюджетны формалаштырганда, республикада керемгә салымны тәэмин итүче зур предприятие вәкилләре белән очрашып, аларның инвестиция проектлары турында сөйләшкәннәр. «Киләсе ел бюджетына керемгә салым буенча салынган саннар барысы да үлчәнеп эшләнгән һәм алар тормышка ашырырлык», – дип ышандырды Радик Гайзатуллин.

Киңәшмә барышында Рөстәм Миңнеханов бурычлар да билгеләде.

– Илкүләм проектларны тормышка ашыруга быел 42 миллиард сум акча биреләчәк. Аның күп өлеше – 30,5 миллиард сумы – федераль казнага туры килә. Искәртеп әйтәм: барлык илкүләм проектлар үтәлергә тиеш. Төзелеп кенә килүче объектларда ел ахырына кадәр эшне тәмамларга кирәк. Киләсе елда да илкүләм һәм дәүләт программаларында мөмкин кадәр күбрәк катнашу зарур, – диде ул.

Бу уңайдан Президент илдә ташламалы ипотеканы озайтуның әһәмиятен

tatarstan.ru

дә билгеләп узды. «Ипотека белән нәрсә булачагы бик зур билгесезлек иде. Әйе, моңа бәйле ниндидер хәвефләр бардыр, әмма бу – бик зур тармак, аңа өметләр зур. Ил Президенты кабул иткән карар төзелеш тармагын тотрыкландыра», – диде Рөстәм Миңнеханов. Билгеле булганча, элегрәк Үзәк банк ташламалы ипотека программасын туктату ихтималы турында хәбәр иткән иде. Берничә көн элек Россия Президенты Владимир Путин аны озайтырга тәкъдим итте. Әлеге программа буенча ставка 8 процент тәшкил итәчәк. «Гаилә ипотекасы»н (ә аның ставкасы – 6 процент) 18 яшькә кадәр ике баласы булганнарга бирәчәкләр.

– Дөньядагы вазгыятьне күрәбез. Махсус хәрби операция зур тырышлык һәм чыгымнар таләп итә. Шуңа карамастан, республикада федераль дәрәҗәдәге бер генә инфраструктура проекты да туктатылмады. Гомумән, республикада бу кадәр зур эшләр башкарылганы юк иде әле. М12не генә алыйк. Юлның Татарстанга туры килгән өлешендә эш дәвам итә, – диде Рөстәм Миңнеханов. Антон Силуановның: «Планда каралганнан тизрәк төзеп бетерәсезме?» – дигән соравына «Үзебезнең план буенча», – дип җавап бирде ул. Сүзен дәвам итеп, М7 трассасын реконструкцияләү кысасында, Чаллы һәм Түбән Каманы урау юлын, Шәле – Баулы трассасына керүче Алексеевск – Әлмәт юлы төзелешен дә искә алды. Татарстанда ике яңа күпер генә салыначак! «Илдә икътисадый хәл әллә ни булмаса, мондый проектларны тормышка ашырып булмас иде», – диде Президент.

Россия финанс министры Татарстанның социаль-икътисадый үсешен югары бәяләде. «Республика яхшы эш күрсәтте. Бюджетка килгәндә, безнең бурыч – бернинди санкцияләргә һәм башкасына карамастан, алда торган йөкләмәләрне үтәүдән гыйбарәт», – диде ул. Рөстәм Миңнехановка карап: «Россия Финанс министрлыгы янәшәгездә!» – дип тә өстәде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Эшкә – аш белән

Быел да фермерлар һәм кооперативлар дәүләт ярдәменнән файдаланды. Билгеле булганча, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ике илкүләм проектны гамәлгә ашыра. Фермерларга һәм кооперативларга ярдәм «Акселерация субъектов МСП» төбәк проекты линиясе буенча тормышка ашырыла. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Наил Залаков журналистлар белән очрашуда әйткәнчә, быел «Агростартап» грантына 94 гариза тапшырылган. 68 фермер 158,9 млн сумлык ярдәм алуга ирешкән. Грант күләме – 1,5–4 млн сум.

– Әлеге программада катнашучылар елдан-ел арта. Беренче елларда аның асылын, мәгънәсен аңлап бетермәгән булсалар, хәзер ярдәм алырга теләүче яшь фермерлар күп. Киләсе елда без аларның эш нәтиҗәләрен күрә алачакбыз. Кемдер алга таба үсәчәк, тагын да эреләнәчәк, – диде Наил Залаков.

Соңгы елларда кооперативларга игътибар артты, дип әледән-әле әйтә киләбез. Наил Залаков алга таба да аларны үстерү кирәклеген әйтте. Аның фикеренчә, кооперативлар – авыл хуҗалыгы продукциясен уңышлы сатуның бер юлы.

– Безнең республикада эре агрохолдинглар белән беррәттән кече бизнес та уңышлы эшли. Болар – фермер хуҗалыклары, шәхси сектор, – ди ул. – Нәкъ менә кооперативлар мондый хуҗалыкларга үсеш алырга, акча эшләргә ярдәм итә. Берничә ел элек шәхси хуҗалыклар үз продукциясен авыл хуҗалыгы оешмаларына караганда ике тапкыр арзанрак бәядән сата иде. Ә хәзер аларга берләшү мөмкинлеге бирелде. Мәсәлән, сөт бәясе формалашуда аның сыйфаты һәм күләме зур роль уйный. Ә мондый кооперативлар, беренчедән, һәркемгә үз эше белән шөгыльләнергә, икенчедән, продукцияне уңышлы бәядән сатарга мөмкинлек бирә. Аларда бәя, чыннан да, отышлырак.

Илкүләм проектлар кысасында, кооперативларга чыгымнарын каплау өчен, акча бирелде. Бу максатлар өчен барлыгы 208,7 млн сум акча бүлеп бирелгән. 200 мең сумнан алып 17 млн сумга кадәр булган субсидия акчасы 43 кооперативка тапшырылган.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, Кукмара, Саба, Азнакай, Биектау, Сарман, Тукай, Түбән Кама районнары проектларда актив катнашкан. Ә менә Чирмешән, Югары Ослан, Әгерҗе, Ютазы, Менделеевск, Зәй һәм Питрәч районнарында бер генә җинүче дә булмаган.

Кооперативларга яңа әгъзалар җәлеп итү буенча да Кукмара алдынгылыкны бирми. Аннан тыш, бу мәсьәләдә Нурлат, Мөслим, Балтач, Биектау, Лаеш районнары да актив эшли. Әлеге районнарда кооперацияләргә 1765 яңа әгъза килеп кушылган. Алар республика планының 73 процентын үтәгән. Тик актив эшләүчеләр белән бергә кооперативларга бер генә кешене дә җәлеп итмәүчеләр дә бар. Әйтик, бу мәсьәләдә 15 район аутсайдер булып тора. Алар – Әгерҗе, Апас, Актаныш, Әлки, Әтнә, Баулы, Бөгелмә, Югары Ослан, Зәй, Яңа Чишмә, Яшел Үзән, Питрәч, Спас, Сарман, Чирмешән районнары.

Өченче юнәлеш – «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперацияләрен үстерү буенча компетенцияләр үзәге»нең чыгымнарын финанслашуга 4,5 млн сум акча бүлеп бирелгән.

Киләсе елда исә илкүләм проектларны тормышка ашыруга 407,7 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан 330,2 млн сум акча тотарга исәплиләр. Проектларның нәтиҗәсе фермер хуҗалыкларының һәм кооперативларның санына карап билгеләнә. Алар 86дан да ким булмаска тиеш. Шулай ук 17 эш урыны булдырырга һәм кооперативларга 2182 яңа әгъза җәлеп итәргә кирәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ОНЫТЫЛДЫ, ДИМӘ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Табиб-пульмонолог Олег Абакумов та вируслардан саклану юлларын күрсәтте:

– Теләсә кайсы салкын тидерү – вирус аркасында. Гриппны башка вируслардан аерырга булыша торган билгеләр бар. Әйтик, кисәк кенә, көтмәгәндә чирли башлыйсыз, 39–40 градуска кадәр температура күтәрелә, күңел болгану, косу кебек билгеләр бар, тамак авырта, борын тыгылган, күз һәм баш сызлый. Чирне кисәк һәм тиз генә йоктырган кебек үк, кисәк һәм тиз итеп аңа җавап та бирергә кирәк. Вируска каршы махсус дарулар эчәргә. Хәлегез начар икән, өйдә калырга, күп йокларга киңәш ителә. Эшлим дип, чир таратып йөрергә кирәкми! Бик күп итеп су эчәргә кирәк. Җылымы, салкынмы – мөһим түгел. Сыеклык күп булырга тиеш! Борынны тоз эремәсе белән юдырырга була. Табиб күрсәтмәсе буенча, башка төр дарулар кулланырга мөмкин.

Шунысы да куркыта: «дуңгыз гриппы» балаларны да аяктан ега. Бу исә алдан хәстәрен күрмәгәннән дә. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының балаларда йогышлы авырулар буенча штаттан тыш баш белгече, медицина фәннәре докторы Владимир Анохин сүзләренә караганда, балаларга гриппка каршы вакцина ясату гадәте юк диярлек. Шуңа күрә сабыйларга кыенга туры килә.

Уйдырма	Чынбарлык
Сарымсак ашап торсаң, чир әләкми	Сарымсакның составында булган фитонцидлар вирусларны үтерергә сәләтле түгел. Күп итеп ашау ашказанын гына авырттырачак.
С витамины булган ризыкларга өстенлек бирергә кирәк	Ул комплекслы тернәкләндерү, организмга ярдәм итү өчен кирәк.
Прививкам бар, мин авырмаячакмын	Прививкасы булган кешеләр аны җиңелрәк уздырып җибәрәчәк. Грипптан соң кала торган «күчтәнәч»ләр дә азрак булачак.
Антибиотиклар дәвалый	Грипп – вирус. Шуңа күрә дә аны дәвалаганда вируска каршы дарулар кулланалар.
Грипп үзе бетә ул, аны дәваларга кирәкми	Дәвалану булмаса, чир йөрәк-кан тамырларына тәэсир итә, пневмониягә китерә ала.

Табиб-педиатр Илдус Лотфуллин да балаларны дәвалауга бәйле кайбер киңәшләре белән уртаклашты.

– Температурага бәйле сораулар күп килә. Тормыш, көнкүрешкә зыян салмый икән, аны төшерергә тырышмагыз. Һаман саен дару эчү дә яхшыга илтми. Аспирин эчәргә ярамый. ОРВИ вакытында анальгин ишеләрне куллану да дөрес түгел. Тәнгә спирт, уксус сөртү дә кирәкми. Чир йоктыруның беренче көннәрендә үк температураның 36,6га калуын көтмәгез. Бу мөмкин хәл түгел! Сабыр булырга кирәк, – диде ул.

Ел йомгаклары

ОЧКАНЫ ДА, ЙӨЗГӘНЕ ДӘ КАДЕРЛЕ

Республика халкы су транспортын үз итеп бетерми. Тиз йөрешле М12 трассасын киләсе елга ук тапшырырга планлаштыралар. Башкалада җәмәгать транспортына билет бәясе артырга мөмкин. Ел йомгакларына багышланган матбугат очрашуында Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов җиткергән яңалыкларның берничәсе генә әле бу.

Һава һәм тимер юл

Быел Татарстанда һава транспортыннан файдаланучылар саны арткан, ә менә йөк ташу күрсәткече, киресенчә, кимегән. Саннар теленә күчсәк, быел Татарстан аэропортлары 4,64 миллион пассажир кабул иткән. Чагыштыру өчен: узган ел бу сан 4,57 миллион булган. Бер ел эчендә республикада һава юллары аша ташылган йөк күләме, 54,8 процентка кимеп, 6,2 миллион тоннадан 2,8 миллион тоннага калган.

Фәрит Хәнифов моны килеп туган вазгыять «җимеш»е дип саный. «Бу юнәлештә эшне туктатырга ярамый. Алга таба үсәргә кирәк. Бар да үтәчәк һәм бу күңелсез вакыйгалар безне көчлерәк итәргә тиеш», – ди министр.

Фәрит Хәнифов фикеренчә, җирле һава юллары булмаса, бездәге аэропортларда пассажирлар саны бермә-бер кимер иде.

– Пассажирлар саны кимү бер аяныч булса, шуңа бәйле рәвештә тулы бер транспорт төренең юкка чыгу ихтималы – икеләтә куркыныч. Әгәр халык авиациядән файдаланмый башласа, моны кабат торгызу бик кыен булачак. Бүген безнең тимер юл транспорты шул хәлдә калды инде. Күп кеше машинага күчеп утырды, – ди министр.

Шулай да Татарстан халкы очкычларга караганда, тимер юл транспортына күбрәк өстенлек бирә икән. Быелның 11 аенда 5,6 миллион кеше поезд һәм электричкаларда йөргән. Узган елның шул чорында андыйлар саны 5,4 миллион булган.

Машина

Халык арасында иң популяр юл булып әле дә булса автомобиль транспорты кала бирә. Быел аннан файдаланган пассажирлар саны 272,7 миллионга җиткән. Узган ел бу сан 237,2 миллион тәшкил иткән. Бер ел эчендә әлеге төре транспорт чарасы ярдәмендә ташылган йөк күләме дә 73,9 миллион тоннадан 112,5 миллион тоннага җиткән.

Моңа юлларның төзеклеге дә зур йогынты ясый, билгеле. Быел Татарстанда юл эшләренә барлыгы 194 миллиард сум акча сарыф ителгән. Түләүле, тиз йөрешле М12 трассасын да бер ел алдан – киләсе елга тапшырырга планлаштыралар. Идел аша сузылачак күпернең дә 48 проценты әзер икән. Министр яңа трасса буйлап хәрәкәт итүнең күпмегә төшәчәген төгәл генә әйтә алмады.

– Бүген бу уңайдан сөйләшүләр алып барыла. Артык югары бәя куйсаң, халык бу юлдан йөрмәячәк. Шуңа күрә башлангыч чорда ул шактый арзан булыр дип уйлыйм. Трассаның Мәскәү аша узган өлешендәге бәяләр белән бездәге хаклар бер үк була алмый, билгеле. Ул да исәпкә алыначак, – диде министр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Су юлы

Республикада су транспортына өстенлек бирүчеләр саны бармак белән генә санарлык. Быел аннан файдаланучылар 317 меңнән артмаган. Узган ел су транспортын үз итүчеләр саны 17 мең кешегә күбрәк булган. Бер ел эчендә Татарстанда су юлы аша ташылган йөк күләме дә 29,4 миллион тоннадан 25 миллион тоннага калган.

Дөрес, саннар әллә ни сөендермәсә дә, министрлыкта су юлын да игътибардан читтә калдырмыйлар. Әйтик, быел республикада причалларны төзекләндерүгә 155,95 миллион сум акча сарыф ителгән.

Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, быел республикада пассажирлар ташучы нибары тугыз судно гына эшләгән. Моннан берничә ел элек, әйтик, шул ук 2019 елда Татарстанда шундый 14 судно исәпләнгән.

– Шул рәвешле без ел саен 1–2 судноны югалта килдек. Шуннан соң Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов яңа суднолар төзергә һәм искеләрен төзекләндерергә кушты. 2023–2024 елларда без алты «Метеор»ны кулланылышка тапшырырга тиеш. Шуларның икесендә инде киләсе елда ук йөреп булачак, – дип ышандырды министр.

Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, якын киләчәктә Татарстанда пассажирлар йөртүче суднолар гына түгел, йөк ташый торганнары да газ-мотор ягулыгына күчерелергә мөмкин.

РЕСПУБЛИКАНЫҢ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЫ ХАЛЫКНЫ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН СОРАУЛАРГА ДА АЧЫКЛЫК КЕРТТЕ.

– Башкалада җәмәгать транспортында билет бәясе 2 сумга артачак, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Әлегә бу мәсьәлә хәл ителмәгән. Сөйләшүләр бара. Билет бәясен арттырганда уйлап эш итәргә кирәк. Халыкка да, аларны йөртүчеләргә дә авырлык килерлек булмасын. «Алтын урталык»ны табарга кирәк.

– Казандагы җәмәгать транспортлары гриппка каршы дезинфекцияләнәчәкме?

– Җәмәгать транспорты даими рәвештә дезинфекцияләнә. Әмма әлегә анда гриппка каршы конкрет чаралар уздыру планлаштырылмый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«ЕЛНЫ УҢЫШЛЫ ТӨГӘЛЛИБЕЗ»

Финанс министрлыгының, Салым һәм казначылык федераль хезмәтләре Татарстандагы идарәләренең уртак коллегиясеннән соң «ВТ» хәбәрчесе Татарстан финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИН белән министрлык эшчәнлегенең төп йомгаклары һәм эшчәнлеге юнәлешләре турында сөйләште.

:: Радик Рәүфович, декабрь – йомгак ясау һәм алга бурычлар билгеләү чоры. Финанс, казначылык һәм салым органнарының уртак коллегиясендә дә йомгак ясалды. Керемнәр буенча бюджетны үтәүнең төп күрсәткечләрен искә төшереп үтмәссезме?

– Бюджетның керемнәр буенча 512 миллиард сум күләмендә үтәләчәген көтәбез. Шуның 421 миллиард сумы – салым һәм салым булмаган керемнәр. Республика бюджетына 360 миллиард сум акча керү күздә тотыла. Җирле бюджетларга – 61 миллиард сум. Бу күрсәткечләр безгә бюджет елын уңышлы төгәлләү мөмкинлеге бирәчәк. Әлбәттә, ел йомгаклары буенча өстәмә керем алу үзмаксат булып тормый. Әмма ул бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын арттыру, бюджет өлкәсе оешмаларының ихтыяҗларын канәгатьләндерү, илкүләм проектларны, социаль һәм иҗтимагый яктан әһәмиятле республика программаларын тормышка ашыруга өстәмә средстволар юллау мөмкинлеге бирәчәк. Шул ук вакытта бюджетны уңышлы үтәү киләсе елга билгеләнгән чараларны финанс белән тәэмин итү өчен билгеле бер мая туплауга китерәчәк.

Коллегиядә финанс министры Антон Силуанов, боларның барысын да исәпкә алып, республика бюджетын үтәүне уңай яктан бәяләде.

– Мәгълүм булганча, республика бюджетына керем китерә торган төп салым – табышка салым. Коллегиядәге чыгышыгызда әйтелгәнчә, быел аның 163 миллиард сум күләмендә керүе көтелә. Ел йомгаклары буенча аның үсеш динамикасы турында нәрсәләр әйтә аласыз?

– Татарстан Финанс министрлыгы табышка салым буенча керемнәргә җитди игътибар бирә. Салым керемнәренең 60 проценты чамасын биреп килә торган зур салым түләүчеләрнең эшчәнлеген анализладык. Ел йомгаклары буенча бу керемнәрнең үсәчәге аңлашылды.

Физик затлар керемнәренә салымга килсәк, ел йомгаклары буенча аларны 111 миллиард сум күләмендә туплау көтелә. Әлеге салымнан да керем артачак.

:: Татарстан Президенты 23 ноябрьдә «2022 елга һәм пландагы 2023–2024 елларга республика бюджеты турында»гы Законга кул куйды. Закон массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыкты. Эшнең хәзерге этабында нинди чаралар күрелә?

– Республиканың бюджет системасына 956 җирле бюджет керә. Бүгенгә барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округларында җирле бюджетлар кабул ителгән. Җирлекләр бюджетлары муниципаль берәмлекләрнең күпчелегендә расланган. Калган муниципалитетларга 21 декабрьгә кадәр җирлекләр бюджетларын раслауны төгәлләргә кирәк. Шуннан соң, бюджет росписен вакытында әзерләү һәм 2023 ел башыннан бюджет процессын оештыру максатыннан, муниципаль берәмлекләр бюджетларын кыска гына вакыт эчендә бастырып чыгару таләп ителә.

Төп бурычларыбызның берсе – ел дәвамында барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү. 2023 елгы бюджетның киеренке булуы көтелү сәбәпле, игътибарыбызны нәкъ менә шуны үтәүгә максималь дәрәҗәдә җәлеп итү кирәк. Форсаттан файдаланып, бюджет процессында катнашучыларның барчасына – министрлыкларга, ведомстволар, муниципаль берәмлекләргә быел финанс-бюджет дисциплинасын тиешенчә тәэмин итүләре өчен рәхмәт белдерәсем килә.

:: Финанс елы ахырына якынлашып килә. Үтәлмәгән ниндидер бурычлар калдымы әле?

– Елның төгәлләнеп килүе тынычланып калуга сәбәп була алмый. Калган көннәрдә безгә министрлыклар, районнар һәм шәһәрләр белән быелгы бюджетның сыйфатлы үтәлешен тәэмин итәргә, керемнәр җыю эшен көчәйтергә, салымнар буенча бурычны максималь дәрәҗәдә киметергә, мөлкәт салымын җыю эшен алып барырга, бюджет һәм бюджеттан тыш чыганакларны җәлеп итеп, чыгым өлеше акчасыннан нәтиҗәле файдаланырга, федераль һәм республика акчасын тулы күләмендә, нәтиҗәле тотуны тәэмин итәргә кирәк. Елны бурычларсыз төгәлләү, бюджет средстволарын тулы күләмендә, максатчан үзләштерү әлеге чараларның нәтиҗәсенә әйләнергә тиеш.

:: Быел Татарстан Финанс министрлыгында коррупциягә каршы көрәш буенча ниндирәк чаралар күрелде?

– Чаралар ел дәвамында ике юнәлештә үткәрелеп килде. Беренчесе – профилактика, аңлату һәм белем эстәү чаралары. Икенче юнәлеш – контроль-ревизия эшчәнлеге.

Быел 11 айда Татарстан Финанс министрлыгының Казначылык департаменты подразделениеләре бюджет акчасыннан ни дәрәҗәдә максатчан, нәтиҗәле файдалануны һәм контракт системасы, коррупциягә каршы көрәш турында законнар үтәлешен ачыклау максатыннан барлыгы 238 тикшерү үткәрде.

:: 2022 ел йомгаклары буенча республиканың дәүләт бурычы күләме 106 миллиард сум дәрәҗәсендә көтелә, дидегез. Бурыч күләме кимемәгән, киресенчә, бераз арткан да әле. Нәрсәгә бәйле бу?

– Иң элек шуны әйтәсем килә: агымдагы елда безнең, элеккечә үк, коммерцияле кредитлар буенча бурычларыбыз юк. Ел башындагы белән чагыштырганда бурыч күләме арту федераль бюджеттан инфраструктураны үстерү өчен кредитлар алуга бәйле.

Тулаем федераль бюджеттан кредитлар алу мәсьәләсенә килсәк, ел йомгаклары буенча бурыч күләме 100 миллиард сум тәшкил итә. Ул озак вакытка реструктурлаштырылган һәм озак вакыт дәвамында түләнеләчәк.

Шуны да билгеләп үтәсем килә: Татарстан кредиттан файдалануга процент түләү буенча да үз бурычларын вакытында үтәп килә. Ел йомгаклары буенча, федераль кредитлар җәлеп итү кысасында Россия Финанс министрлыгы белән килешүләрдә билгеләнгән барлык күрсәткечләргә ирешеләчәк.

Җыеп әйткәндә, 2022 ел йомгаклары буенча бюджет күрсәткечләре үтәләчәк. Бюджет чыгымнары тулысынча финансланачак, бюджет акчасын үзләштерүгә контроль даими алып барылачак. Шуннан салмак кына киләсе елга кабул ителгән бюджетны үтәүгә күчәргә тиешбез. Төп бурычыбыз берәү генә, ул да булса – барлык бюджет чыгымнарын үз вакытында һәм сыйфатлы финанслау.

Форсаттан файдаланып, редакция хезмәткәрләрен һәм газета укучыларны якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм! Барлык башлангычларыгызда уңышлар, саулык-сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс көч-дәрт телим!

Хәл ителгән мәсьәлә

Баскычы да бар, уты да яна

Редакциягә Биектау районының Коркачык авылында яшәүчеләр, поезд юлының 835 нче тукталышында платформадан төшәргә баскыч юк, дип мөрәҗәгать иткән иде. Казан шәһәренә бару өчен ясалган ягы бик әйбәт булса, кайтканда кем ничек булдыра ала – шулай төшкән. Шулай ук ул тирәдә баганаларда ут та янмаган. Караңгыда телефон уты белән йөрергә туры килгән. Без Коркачык авылы халкын борчыган проблеманы Горький тимер юлының Казан төбәге матбугат үзәгенә хәбәр иттек. Белгечләр мәсьәләгә ачыклык кертергә вәгъдә бирде, проблеманы җиткергәнгә рәхмәт белдереп, кыенлыклар тудырган өчен пассажирлардан гафу үтенде. Шуннан соң киңәшмә уздырып, тимерьюлчылар баскыч урнаштыру һәм платформада өстәмә яктырту мәсьәләләрен хәл иткән.

Бүген инде авыл кешеләре сөенеп: «Башта баскычны, аннан утларны куйдылар. Хәзер инде йөрергә куркыныч түгел. Тимерьюлчыларга рәхмәт», – дип хәбәр иттеләр.

Сәрия МИФТАХОВА

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
09.12.2022 теркәлде, № 10165

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында

02.12.2022 Казан ш. № 3733-р

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 2016 елның 03 июлендәге 237 – ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә 2022 елда дәүләт кадастр бәяләве үткәрү турында» 2021 елның 04 июнендәге № 1729-р карарын гамәлгә ашыру максатларында:

1. 2022 елның 01 гыйнвары торышына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр бәяләвенең беркетелгән нәтиҗәләрен (алга таба – Нәтиҗәләр) расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында (www.mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми басмалары булган «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Э.М. Дияровка йөкләргә.

Министр Ф.Ә. Әһлиуллин

Искәрмә: Дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы сайтында (адресы: https://mzio.tatarstan.ru/deystvuyushchie-rezultati-gosudarstvennoy.htm) урнаштырылган.

«МИН – САБЫЕ ҺАМАН ҖИҺАННЫҢ...»

Юбилей

«Ачлы-туклы узган балачагымда, 80 яшемә җитәрмен дә сезнең белән очрашырмын дип уйламый да идем...» Язучы, шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим үзенең 80 яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсен әнә шундый сүзләр белән башлады.

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә узган чарага Айдар Хәлимнең якыннары, татар дөньясы өчен билгеле шәхесләр һәм туган ягы Башкортстанның Миякә районыннан кунаклар килгән иде. Юбиляр, тамашачысы алдына чыккач, сүзен рәхмәттән башлады. Татарстан җитәкчелегенә дә, аны хөрмәт итеп килгән кунакларга да җылы сүзен кызганмады ул. Ә соңыннан үзе иҗат иткән берничә шигырен дә укыды.

Юбилей кичәсе котлауларсыз булмады, билгеле. Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров Айдар Хәлимнең милли күтәрелеш чорларында алдынгы сафларда булуын искәртте.

– Татар тарихында һәм халык күңелендә тирән эз калдырган Айдар абыйның үзенчәлекле, киңкырлы шәхес булуы әле күп тапкыр әйтелер. Минем аның татар җанлы, милләт җанлы кеше булуына басым ясыйсым килә. Милли күтәрелеш чорларында, бигрәк тә Башкортстан татарларының мәнфәгатьләрен яклаганда, алгы сафларда Айдар абый Хәлим иде. Мин аны бөркеткә тиңләр идем. Сәяси вазгыятьнең нинди булуына, җилләрнең кайсы яктан исүенә карамастан, ул һәрвакыт үткен, кыю һәм салмак фикер иясе, батыр йөрәкле милләт баласы булды, ә бүген ул – милләт агасы, – диде Данис Шакиров. – 80 яшегездә Казаныбызның иң матур залларының берсендә елмаеп утырасыз икән, тормышыгыз заяга узмаганны аңлыйсыздыр. Лаеклы хезмәтегез югары бәяләнде: дәүләт бүләкләре бирелде, күпсанлы китапларыгыз басылып чыкты.

Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, юбилей иясенә шәмаил бүләк итеп, Коръәни Кәримдәге бер сүрәнең тәфсирен сөйләде.

– Мөхәммәт пәйгамбәргә (с.г.в.) дошманнары, син – пәйгамбәр түгел, син – шагыйрь генә, дип, яла яккан. Аларга җавап итеп: «Шагыйрьләрнең колагына иблис пышылдап, алар үзләре дә саташып, кешеләрне дә саташтырып йөри. Әмма араларында иман китергәннәре дә бар, аларның сүзенә колак салырга кирәк», – дигән ул. Айдар Хәлим – менә шундый шагыйрьләрнең берсе, минемчә. Хакыйкатьне әйтеп бирүче шагыйребез ул безнең! Ак түбәтәй киеп, җыйнак кына татар сакалы үстереп, татар күңеленә якын шигырьләрен ничек дәртләнеп, илһамланып сөйләде бит бүген! – диде ул.

«Татар-информ»

Шуннан сүзне юбилярның әшнәләре, театр әһелләре Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Илдус Әхмәтҗановка бирделәр.

– Ул әсәрләрендә Татарстан, Башкортстан, Россия турында гына түгел, дөньядагы, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр турында фикерләрен җиткерә, бар кешелек дөньясына кагылышлы мәсьәләләр турында сөйли. Миңа калса, ул Нобель премиясенә тәкъдим ителергә тиеш. Ләкин аңа әле Тукай бүләге дә бирелмәгән, – диде Равил Шәрәфиев.

Әзһәр Шакиров исә Айдар Хәлимне көрәшче дип атады.

– Бу сыйфатлар тумыштан салынган, күрәсең. Татар халкын уятыр өчен, хөрлеккә бару юлын яктыртыр өчен тугансыздыр сез. Милләткә хезмәт итү – бөек максат ул. Ә ул гомере буе шушы максатка хезмәт итте. Татар халкының бөеклеген ачып бирергә омтылды, татар халкының башка милләттән ким түгеллеген күрсәтте. Мондый шәхес онытылмаячак, – диде ул.

Билгеле, юбилярның өч сылуы – өч кызы да сүз алмыйча калмады. Айдар Хәлимнең Илсөяре, Зөлфиясе һәм Кадриясе әтиләренә видеокотлау төшергән иде. Төпчеге һәм өлкән кызы татарча котласа, уртанчы кызы изге теләкләрен рус телендә җиткерде.

Айдар Хәлимнең иҗат кичәсендә котлаулар җырлар белән үрелде. Әдип язган шигырьләргә Зөлфия Тәхаветдинова иҗат иткән җырлар иде ул. Аларны Руслан Сәйфетдинов, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Гүзәл һәм Арслан Сибгатуллинар, Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Алмаз Хөсәенов, Илнар Шәрәфетдинов һәм башкалар яңгыратты.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Әкияттә кунакта

Чыршы тирәли әйлән-бәйлән, әкияти тамаша, Кыш бабай һәм Кар кызы. Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында беренче хәйрия чыршы бәйрәме узды. Тамашаны быел әтиләре мобилизацияләнгән балалар карады.

Яңа ел бәйрәменә 4 яшьтән 7 яшькә кадәрге 205 бала чакырылган иде.

– Бүген без Яңа ел хәйрия акцияләре сериясен башлыйбыз. Быел без аларны мобилизацияләнгән гражданнарыбызның балалары өчен оештырабыз. Чыршы бәйрәмнәре, нигездә, мәктәп яшендәге балалар өчен үткәрелә. Шуңа без нәниләрне сөендерергә булдык, – ди Татарстан Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова. – Быел бу категория гаиләләрне үз канатыбыз астына алабыз. Беркемне дә игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Тиздән бөтен республика буенча мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләренә, күпбалалы, инвалид балалары булган гаиләләргә Яңа ел белән котларга килә башлаячакбыз. Балалар өчен кайгырту һәм игътибар беркайчан да артык булмый. Әтиләр гаиләләренә тизрәк кайтсыннар иде. Без барысын да бик көтәбез.

Әлеге акцияне «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе оештыра. Ярдәмгә мохтаҗ булган балалар өчен үткәрелә торган бәйрәм инде сигезенче тапкыр уздырыла. «Мәрхәмәт» җитәкчесе Алсу Нәбиева әйтүенчә, «Бердәм Россия» партиясе тарафыннан мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләренә ярдәм итү буенча зур эш башкарыла.

– Безнең «Мәрхәмәт» хатын-кызлар берләшмәсе инде ничәнче ел рәттән төрле категориядәге балалар өчен чыршы бәйрәмнәре үткәрә. Без балаларга чын бәйрәм ясарга һәм кечкенә кунакларыбызның күңелләрен күрергә телибез. Безнең берләшмәдән тагын берничә шундый чара булачак, – диде ул.

Яңа ел бәйрәме балаларны чын могҗиза дөньясына чумдырды. Чыршы тирәли әйлән-бәйлән, мавыктыргыч конкурслар, җыр-бию... Балалар шатлыктан балкыды. Нәни тамашачылар «Яңа елның тылсымлы төше» дигән әкият тамашасын карады. Балаларны төп геройлар – Кыш бабай һәм Кар кызы да котлап, бүләкләр өләште.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышын 2022 елның 23 декабрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 декабре
№ 1746-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 367-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

2. «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 360-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 366-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 359-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 200890-8 номерлы федераль закон проекты турында (бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә, рәсми спорт ярышлары җиңүчеләренә аерым хокуклар бирү өлешендә).

6. «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 232776-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юлларда урнашкан күперләрне һәм тоннельләрне эксплуатацияләү хакында).

7. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{5} һәм 39^{10} статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

8. 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 декабре
№ 1747-VI ДС

С 17 по 21 декабря 2022 года
РАСПРОДАЖА
УНТЫ



ИЗ ЯКУТИИ
из оленины (камус)
женские и мужские
цена от 5000
г. Казань, Вахитовский район, улица ВИШНЕВСКОГО, д. 12
(вход слева от магазина «Йола»), ориентир – магазин «Все инструменты», расположен рядом с помещением, остановка «ул. Калинина».
реклама 16+

ТЕХНИКА БЕЛГЕЧЕ ТӘЛГАТЬ ӘҮХӘДИЕВ: *«Бишле»гә укысам, министр булыр идем»*

Илдар Мөхәммәтҗанов

Техника ватылса, Тәлгать кирәк! Кукмара районының Камышлы авылында яшәүче Тәлгать Әүхәдиевнең телефоны тынып торганы юк. Алтын куллы белгечне Кукмарада гына түгел, Балтач, Саба районнарына кадәр чакырталар. Барысына да ничек өлгерә икән?

Мәктәптә укыганда билгеләре белән мактана алмаса да, эше белән күпләрнең борынына чиертә ул. Кесәсендә дә һәрвакыт акча була. Үзе турында уены-чынын бергә кушып: «3ле»гә укыган Тәлгать мин, «5ле»гә укысам, министр булыр идем», – дип шаярта. Яхшы белгеч булыр өчен үзеңә нәрсә кирәген кечкенәдән белергә кирәктер ул. Әнә Тәлгать Әүхәдиев кебек! Аңа техника җене 6–7 яшьтә үк кагылган. Дөресрәге, ат караучы булып эшләгән әтисенә ияреп, ындыр табагына төшкәндә. Юк, малайны ашлык көшелләре дә, андагы эшчеләр дә, техника да кызыктырмаган. Кукмарадан килгән күчмә төзәтү остаханәсендәге абзыйларның тимер-томыр эчендә кайнашуын күзәтергә яраткан ул. Тимер юлда эшләгән әнисе Гөлчирә дә аның өчен үрнәк булган. Электр чыбыкларына якын килергә курыкмаган, авария була калса, утларны рубильниктан үзе сүндергән. 10 яшьтә инде кечкенә техник ут кертергә өйрәнгән, күршеләренең мотоциклын ремонтлаган. Берзаман физика укытучысы Нәкыйп Хисанов аны Березняк авылына кино күрсәтергә чакыра. Ләкин укытучысына укучысының уңышларын күрергә язмый. Ул үзенең туе көнне буада батып үлә.

16 яшьлек егет Казанда суыткыч төзәтүчегә укый. Казахстанда армиядә хезмәт иткәндә дә белгәненең кирәге чыга. Аннан кайткач, райпо системасында 25 еллап суыткычлар төзәтә. Соңгы 15 елда шундый ук хезмәтне фельдшер-акушерлык пунктларына күрсәтә. Район хастаханәсендәге 65ләп медпункт дигән сүз бу. Ярты штатта эшләсә, калган очракта заказлар буенча өйләргә, оешмаларга йөри. Элек кер юу машинасы, телевизор, башка көнкүреш җиһазларына да икенче сулыш биргән. Берсендә хәтта Удмуртиянең Кизнерь урманнарына ватык пычкы төзәтергә чакырганнар. Андагы сазлыкны да, 30–40 градуслы эссене дә онытмый ул. Элегрәк күрше районнарга мотоцикл белән барып, атна буе техника ремонтлаган. Тик соңгы вакытта суыткычларга гына заказлар ала.

– Бер суыткычның «йөрәге»н, ягъни компрессорны 2–2,5 сәгать алыштырам. Кайбер белгечләр, бер сәгатьтә дә куеп китәбез, диләр. Алай дөрес булмый. Мин ашыгып эшләмим. Ватык дип чүплеккә чыгарып ыргыттыру ягында да түгел. Яхшы табиб тешне суыртырга кушмый бит. Мин дә, гаебен табып, хуҗаларына файда китерсен дип тырышам, – ди 41 ел стажлы белгеч.

Хәзер бит белгечләр өйгә чактырткан өчен дә акча сорый. Бәясе 1 мең сумнан да ким түгел. Тәлгать абыйга да иң элек шул сорауны бирәләр. Андыйларга, теләсәгез, бушлай карыйм, дип әйтә икән. «Гади кешеләр акчаны түләргә тырыша. Киресенчә, байлар акча саный. Чикләүләр кертелгәч, җиһазлар өч мәртәбә кыйммәтләнде бит. 400–500 мең сумлык запчастьлар гына сатып алдым. Күп дигәндә, 3 мең, ким дигәндә, 700–800 сум алам», – ди ул хезмәт күрсәтү турында.

Көндәшлек турында да сораштык. Районда барлыгы шундый 3–4 белгеч бар икән. «Эш барыбызга да җитә, җитешеп булмый», – ди Тәлгать әфәнде. Үзенең кадерле белгеч икәнлеген соңгы елларда гына аңлый башлаган. Бервакытта да игъланнар бирмәгән. Хәзер барысы да аны интернеттан таба. Үзенең генә 15ләп шәкерте бар икән. Алар төрле районнарда хезмәт куя. Белгеч әйтүенчә, кайчак тәҗрибә белән ерак китеп булмый. Ни өчен дигәндә, замана техникасы үзгәреп тора. Хәзер компьютер аша төзәтү гадәткә кереп бара. Бу очракта аңа шәкертләре булыша.

Без килгәндә, аның 45 чакрымдагы Татар Толлысы авылына барырга җыенган чагы иде. Аңа кадәр Саба Лесхозында ашханә, кибетләрдәге җиһазларны ремонтлаган икән. Сүзгә хатыны Рәмзия ханым кушылып: «Төнге 12дә кайткан чаклары да була. Бер шалтыратканда, районның – бер, икенчесендә икенче башында ул. Бар җиргә дә өлгерә. Көнгә 200әр чакрым юл үтә. Җәй көне 2–3 суыткыч ремонтлый, – ди. – Берсендә авылыбыз егетен иртүк сәгать 4тә армиягә озатырга кирәк. Тәлгать безнең гармунчы бит. Үч иткәндәй, Лесхозга эшкә чакырдылар. Иртә белән кайтты да тизрәк озатырга китте».

Күршесе Галия апа да: «Ярый әле Тәлгать бар», – дип сөенә. Беркөнне төнлә суыткычы эшләми башлаган аның. Заманча техника суыкта эшләми, дип аңлаткан күршесе. Кешегә кайчак шундый бер киңәш тә җитә.

Сәрия МИФТАХОВА

Озак хезмәт итсен өчен, суыткычны ничек карап-тәрбияләп торырга кирәк?
Чит ил суыткычлары артында радиатор-конденсатор бар. Елга бер мәртәбә шуның тузанын суыртырга кирәк. Моторы ябык булса, җилләткечен чистартырга онытмагыз. Шул чакта суыткыч озак хезмәт итәчәк.

Югалту

ХАЛЫК ЯРАТУЫН БЕЛЕП КИТТЕ

Халыкчан җырчы иде. Татарстанның атказанган артисты Эльмира Сөләймановны иҗатташ дуслары да, тамашачылар да әнә шулай дип күңелләрендә саклар. Җомга иртәсе күңелсез хәбәрдән башланды. 40 яшен тутырган җырчы таң алдыннан бакыйлыкка күчкән.

Аның ике сабые ятим, ире ялгыз калды. Кызы Дианага – 16, улы Артемга 9 гына яшь әле. Барыбыз өчен дә әйтеп бетерә алмаслык югалту. «ВТ» журналисты Эльмира Сөләйманова хакындагы истәлекләрне барлады.

14 ел баянчысы булып эшләгән Фәйзелхак абый Хәлимов Эльмираның кинәт китеп баруына әле дә ышана алмый.

– Мин аны 16 яшеннән бирле беләм. Ул чакта «КАМАЗ» мәдәният сараенда эшли идем. 16 яшендә «Сердәш» ансамбленә килеп керде ул. Ул чакта җырлавын ишетеп, хәйран калган идем. Шунда аннан талантлы җырчы чыгасын сизеп алдым, – ди Фәйзелхак абый. – Башта аның белән зур чараларда гына катнашып йөрдем. Без аңа ике баянчы уйный идек. Икенчебез Руслан башка төркемгә киткәч, үзем генә уйный башладым. 2017 елда төп эшемнән китеп, Эльмира белән гастрольләрдә йөри башладык. Тамашачы аны бик ярата иде. Ул сәхнәгә чыгып басуга, залга әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык җылылык тарала иде. Хәтта, тавышым бетеп тора әле дигәндә дә, кулына микрофон тотуга, үзеннән-үзе җырлап җибәрә иде. Аның белән эшләү бик рәхәт булды. Мин кем дигәне булмады. Тәкәббер түгел иде. Бергә ашадык, бергә юлда йөрдек. Мин аның йөртүчесе дә идем. Төркемгә карата бик тә ягымлы булды. Кешеләрне яратты. Бу хәлгә мин бик озак ышана алмамдыр әле.

Фәйзелхак абый, Эльмираның күңеле тулы моң иде, ди. Аның гомер буе йөрәге яралы булган. Әтисез үсү, авырлыклар күрү сагышын ул җыр белән баскан. Аңа өч яшь чагында әтисе белән әнисе аерылыша. Ул туган ягы Аксубай районының Иске Ибрай авылында ел саен май бәйрәмнәрендә концерт куйган. Эльмира бер генә хәйрия концертын калдырмады, дисәк тә, арттыру булмас. Әле менә 14 декабрь көнне Казанга да килергә җыенган. Биредә узасы хәйрия чарасында катнашырга исәпләгән. Әмма бик каты йөткергәч, бара алмавын хәбәр

иткән. Фәйзелхак абый белән гел элемтәдә булган алар. Башта сөйләшеп торганнар, соңрак «Ватсап» аша язышканнар.

– Тавышы бик беткән иде. Ютәлем көчле, үләм, ахры, диде. 18 декабрьдә Нефтекама шәһәрендә банкетта чыгыш ясыйсы иде. 15е көнне кичтән, банкетка бара алмыйм, дип язды. Иртән исә ире вафатын хәбәр итте. Таң белән сәгать 4тә ире Дмитрий гырылдаган тавышына уянып китсә, җан биреп ята икән. Бик авыр хәл. Якыннарын юатыр сүз таба алмыйм, – ди Фәйзелхак абый.

Баянчысы Эльмираның гел тере тавышка җырлавын, бер дә плюс кулланмавын әйтте. «Андый җырчылар сирәк ул, моңы йөрәгеннән чыкканга, тамашачыга барып җиткәндер»,– диде ул.

Композитор Флера Талипова да Эльмираның гел күңелгә үтеп керерлек, мәгънәле җырлар сайлаганын әйтә. Күп җырлары сагышлы иде. Ул җырларның сикереп җырлый торганнарын түгел, сузып моңлана торганнарын сайлаган.

– «Ярый әле дуслар бар» дигән җырымны сорап килде. Аралашып киттек. Гел сөйләшеп тора идек. Күп җырларымны башкарды. Күңеле ярала булганга, күбрәк моңсу җырларны сайлады. Авырлыкны күп күргән бала иде. Инде менә матур гына яшәгәндә, китеп тә барды. Үкенечем калды – концертларында катнаша алмадым, – ди Флера апа. – Эльмира сәхнәдә үз юлын тапкан иде инде. Аны халыкка таныту өчен Дәниф Шәрәфетдинов зур көч куйды. Тамашачы елар да онытыр, ә менә балалары нишләр? Сабыйларга әни кирәк…

Күп еллар бергә иҗат иткән җырчы Ильмира Нәгыймова Эльмирага дистәгә якын җыр язып биргән була. Хәтерләсәгез, алар бергәләп концертлар да куеп йөргән иде әле. Бүген Ильмира якын кешесен югалтуны авыр кичерә. Күңелендә төрле хисләр аның.

– Бик талантлы иде ул. Бар нәрсәне йөрәгенә якын алды. Еш кына үз эченә бикләнә торган гадәте дә бар иде. Без бергә 2 ел эшләдек. Якын дуслар булдык. Әмма бервакыт аның дусты арабызга керде. Шуннан соң бер-беребезгә карата суындык, – ди Ильмира. – Эльмираның үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч, башта ышанмадым. Шаярталар дип уйладым. Кызганыч, дөрес булып чыкты. Эльмира бик кешелекле иде. Беркайчан да бер әйберен дә кызганмады. Үзенә калмаса калмый, синә бирер иде. Әле бер ел элек яңадан сөйләштек. Бергә эшли башламакчы булдык. Эльмира коронавирусны да авыр кичергән иде.

Кемгә генә шалтыратма, барысы да өнсез калган. Кайберәүләр ни әйтергә белмичә торды. Әмма барысы да, аны халык яратты, диде.

– Без Эльмира белән өч ел концертлар куеп йөрдек. Башта бергәләп дуэт башкардык. Безне халык яратып кабул итте. Аннары тагын җырлар яздырдык. Шулай итеп, дусларга әйләндек, бергә иҗат итә башладык, – ди җырчы Рамил Галимҗанов. – Аның үзенә генә хас тавышы бар иде. Кешеләргә ягымлы булды. Нинди генә хәл булса да, күңелен төшермәде. Тамашачы аны бик яратты. Халык яратуы бернәрсәне алыштыра алмый. Эльмира шул яратуны тоеп, белеп китте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЧАБАТАЧЫ ШАМИЛ

Шөгыль

Эш буенча Биектау районына баргач, Кече Рәс авылына – чабата үрүче Шамил абый янына да кереп чыгасы иттек. Инде онытылып барган әлеге шөгыльне яшәтүче аксакал белән якыннан танышасы килде. Әмма Шамил абыйны алай гына өйдә туры китерәм димә икән! Без килгәндә, ишегендә йозак иде. Тынгысыз җан гел хәрәкәттә. 92 яшьлек бабайның ялт итеп машинада җилдерүен белгәч, кызыксынуыбыз тагын да артты. Ул кайтканны ничек тә көтәсе иттек.

Зөлфия Хәлиуллина

Шыгырдап торган нык бүрәнәле йортның капка төбенә җәһәт кенә кайтып туктады ул. Ул да үтмәде, Шамил абый үзе дә күренде. «Күрше авылга дустымның хәлен белергә барган идем», – диде ул, машинадан чыгуга. Чиста-пөхтә киенгән, башында чал чәчнең әсәре дә күренми. Шамил абыйга 92 яшьне һич биреп булмый, кыскасы.

Гаҗәпләнүебезне күреп булса кирәк: «Гел юлда йөреп торам мин. Казанга да, Питрәчкә дә еш барам. Бу инде – үз гомеремдә алган унынчы машинам. Биш «Урал» мотоциклым да бар иде», – ди ул.

Сөйләшә-сөйләшә, Шамил абыйның өенә узабыз. Өйгә килеп керүгә, борынга юкә исе бәрелә. Йорт хуҗасы әле яңарак кына бер партия чабата әзерләп бетергән икән. Осиноводагы иҗат коллективы заказ биргән булган. Шамил абыйның сүзләренә караганда, үткәннәр кайтавазы саналган чабатага бүген дә сорау зур икән. Ул үргән чабаталарның даны чит илләргә үк таралган. Америка, Германиягә барганда, күчтәнәч итеп чабата алып баручылар да булган.

Шамил абый үзе чабата үрү белән мәктәптә укыганда ук мавыга башлаган.

– Чабата үрү өчен юкәне Казаннан алып кайтам. Монда хәзер юкә бик юк, агачлар картаеп бетте. Юкә агачын алырга каен җиләге пешкәч, бер атнадан барам. Шунда бик яхшы куба ул. Аннары юкәне кайнатам. Ул кайнап йомшагач, чабатаны шундук ясап бетерергә кирәк. Катса сына. Төрле калыпка салып эшлим, – ди ул.

Шамил абыйның чабаталары сап-сары булып ялтырап, хуш исе белән әллә каян үзенә җәлеп итеп тора. Болай матур итеп чыксын өчен, юкәне бик озак эшкәртергә кирәк икән. Бер пар чабатаны бер көн үрә ул. Мәшәкате күп. Шуңа күрә бер чабатаны мең сумнан да кимрәк бәягә сатмый.

– Башкалар ясаган чабаталарны карап торам, кап-кара. Юк белән мактаналар. Менә чабата нинди була ул. Көлеп тора! – ди Шамил абый үзе.

Җәй көне олтыракка – кипкән печән, яз-көз, кыш киез итек балтырларын кисеп сала икән. Яз көне су үтмәсен өчен, агачтан күтәртмә беркетә.

Чабата үрү – Шамил абыйның күңел эше. Үзе гомере буе балта остасы булып эшләгән ул. Көндез колхозда эшләсә, кичен, төнлә мунчада тәрәзә, ишекләр ясаган. Бүген торган йортын да 70 яшендә үз куллары белән салып чыккан ул. Аңарчы 30 ел Казан янындагы Күлле бистәсендә яшәгән.

– Моннан унбер ел элек тормыш иптәшем Һәдия вафат булды. Бик матур яшәдек. Акыллы, гыйлемле кеше иде. Кан басымы белән китеп барды. Биектау хастаханәсендә карамадылар, Казанга алып бардым. Башта кызымда торды. Биш ай авырды. Кызым эшкә киткәндә, мин барып карый идем. Җәен авылга, үзебезнең өйгә алып кайттым. Өйгә өстәп, юыну бүлмәсе, бәдрәф төзи башладым. «Сине быел шәһәргә илтмим, үзем карыйм», – дидем. Бура бурап куйдым. Карчыгыма анда торырга насыйп булмаган икән, үлеп китте. Әмма ул бүлмәне ясап бетердем барыбер, – ди Шамил абый.

Бүген ул болын кадәр өйдә берүзе тора. Ике кызы белән бер улы бар. Олы кызы, өч көнгә бер кайтып, әтисенең хәлен белешеп, ашарга пешереп китә икән. Шулай да ялгызлык дигәнең барыбер үзен сиздерә. «Кыш көне вакыт бигрәк тә озак уза. Картлык көнемдә янәшәмдә бер иптәш булса, бик шат булыр идем», – ди ул.

Буш вакытында чабата үрүдән тәм таба Шамил абый. Күзне бетерә, дип, телевизор да карамый. Сау-сәламәт килеш, яхшы хәтер белән шушы яшенә җитүенең төп сәбәбен исә начар гадәтләре булмауда күрә.

– Үз гомеремдә бер тапкыр да аракы эчмәдем, тәмәке тартмадым. 1941 елны кызамык белән авырдым да шуннан соң бер колагым ишетмәс булды. Әти сугышка киткән җиреннән кайтмады. Әни тәрбияне бик каты бирде. «Синең бөтен нәрсәң булыр. Ходайга ышан», – диде. Бу сүзләрне беркайчан да истән чыгармадым. Гомер буе хезмәт белән, дөрес, хәләл яшәдем, кеше рәнҗетмәдем, – ди Шамил абый.

Китәр алдыннан ишек кырыенда эленеп торган чабатага күзебез төште. Баксаң, аның анда торуының да хикмәте бар икән. Шамил абый юлга чыкканда шуңа: «Әй, Аллам, исән-сау йөреп кайтсам иде», – дип укып, акча сала икән. Шулай эшләсәң, юл һичшиксез уңа, ди. Чабатада җыелган акчаны исә мәчеткә илтеп бирә яки мохтаҗларга тарата ул. Әнә шулай тормышының, яраткан шөгыленең һәр мизгеленнән тәм табып яши Шамил абый!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 387

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+